| | | |
|---|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2019 елның 16 апреле Балык Бистәсе штп. № 22

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе штп. территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында

2009 елның 28 декабрендәге “Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт көйләве нигезләре турында” 381 -ФЗ номерлы Федераль законның 10 маддәсен, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 13 августындагы “Муниципаль милектәге җирләрдәге яки җир кишәрлекләрендәге, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдәге яки җир кишәрлекләрендәге стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында” 553 номерлы карарын, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының 2011 елның 26 февралендәге “Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары тарафыннан стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын төзү һәм раслау тәртибен раслау турында” 34-ОД номерлы боерыгын үтәү йөзеннән КАРАР БИРӘМ:

1. Кушымтага ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе штп. территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын расларга.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма Комитетының 2014 елның 17 гыйнварындагы “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге . территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында” 1 номерлы карарын көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында: 422650,Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Балык Бистәсе штп., Ленин урамы, 48А йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Җитәкче М.В. Мәгыйзов

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 16 апрелендәге 22 номерлы карарына кушымта

## Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе штп. территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасы

| № п/п | Стационар булмаган сәүдә объектларының исеме һәм урнашу урыны | Реализацияләнә торган товарның ассортименты | Стационар булмаган сәүдә объектларының тибы | Сәүдә эшчәнлеген гамәлгә ашыручы кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан стационар булмаган сәүдә объектларын файдалану турында мәгълүмат | Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру чоры |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Ленин урамындагы 52А һәм 58 номерлы биналар арасында | яшелчәләр, фруктлар (ШЯХ продукциясе) | лоток, контейнер | сәүдә итү | сезонлы сәүдә |
| 2 | Н.Некрасов урамы, 2А | эчемлекләр (ш.и. сыра продукциясе) | киоск, павильон | сәүдә итү | сезонлы сәүдә |